КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 апрель г.Казань № 303

Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсенә Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булып торган автоном коммерциячел булмаган оешмаларның идарә органнарында Татарстан Республикасы вәкилләренең катнашу тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 июнь, 466 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсенә бүбәндәге Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләп куярга:

| | |
|---|---|
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улын | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйз улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын, идарә әгъзасын |
| Чернова Марина Иннокентьевнаны | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының инвестицияләр җәлеп итү эшчәнлеген координацияләү бүлеге башлыгын, идарә әгъзасын |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улын | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Казначылык департаменты директорын, идарә әгъзасын |

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин Эдуард Илтөзәр улын | Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты директорын, идарә әгъзасын (килешү буенча). |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсенә Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләп кую һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану турында» 2021 ел, 18 август, 747 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин